| ГЛАВА БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БИЛӘР АВЫЛ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.10. 2020 с. Билярск № 1

**Гражданнар җыенын үткәрүне башлап җибәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25_1 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Советы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Биләр авылында гражданнар җыенын уздыруны түбәндәге сорау буенча башлап җибәрергә: «Биләр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту);
- авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү;
- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү;
- техниканы карап тоту (трактор, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);
- күпер һәм җәяүлеләр кичү юлларын карап тоту һәм ремонтлау.
ӘЙЕ ЮК».
2. Шәмә авылында гражданнар җыенын уздыруны түбәндәге сорау буенча башлап җибәрергә: «Биләр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум

күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту);
- авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү;
- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү;
- техниканы карап тоту (трактор, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);
- күпер һәм җәяүлеләр кичү юлларын карап тоту һәм ремонтлау.

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Биләр авыл җирлеге башлыгы** **Г.Г.Хәбибуллин**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БИЛЯРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ